

Кочле рухлы, хезмәт соючән Ләмберәнен Ерзиннар гаиләсе турында язмабыз.
Гаилә учагын саклаучы Ләмберә авылынын Крестьянская урамындагы зур, матур йортны Камиль Али улынын бабасы Садретдин салган. Ул яшь хатынын, Хәлимә Фәйсхан кызын, шушы йортка алып килгән. Ойдә анын әти-әнисе генә тvгел, абыйсы Госман да, гаиләсе белән яшәсә дә, барысына да урын житкән. Ул заманда аларнын хужалыгы хәлле саналган; сонынннан кулаклар дип сорvгә сәбәп булган.  Дорес, Али Садретдин улына тимәгәннәр - сугышчан хезмәтләре коткарган (Урта Азиядә басмачлар белән гражданнар сугышында катнашкан чор турында, инвалид булып кайткан Боек Ватан сугышынын фронт коннәре турында да искә тошерергә яратмаган).      Ә бит Али Садретдин улы Ерзин Дан ордены белән бvләкләнгән! Тыныч заманда Али Садретдин улы Ләмберәнен «Победа» колхозында кладовойчы булып эшләгән һәм председатель Маринов аны бу эшкә намуслы монәсәбәте очен хормәт иткән.
Ерзиннар гаилә учагын саклаучы, ун бала тәрбияләгән гади авыл хатыны Хәлимә Фәйсхан кызы язмышы кызыклы. Ул Ләмберә районынын Черемиш авылы бае Сюбаевлар гаиләдә vскән. Хәлимәнен әти-әнисен соргенгә куганнар һәм аларнын яраткан хужалыгы тозелә торган колхознын нигезе итеп алынган. Ярый, бу да шул чактагы чынбарлыкнын бер ягы....
Хәлимәгә килгәндә исә, әтисе Ләмбердә хормәт казанган Ерзиннар гаиләсе белән туганлашырга теләп киявгә биргән. Чыннан да Халимә иренен әти-әнисенә чын ярдәмче, игелекле хужабикә, кайгыртучан ана, ой учагын саклаучы була. Тәвәккәл, энергияле хатын буларак, vз эшен дә оештыра алган. Шулай, Ярославльдәге туганнарын кvрергә баргач, сепараторлар алып кайткан һәм аларны Ләмберә районынын тирә-як авылларында яшәгән ныклы хужалыклар хужаларына арендага биргән. Ә алар монын очен май белән тvләгәннәр. Әлбәттә, семья ач булмаган.
- Мин әле дә әни ясаган атланмайнын тәмен һәм хуш исен хәтерлим, - дип искә ала Камил Али улы Ерзин. - Кибеттән андый май сатып алып булмый! Сонрак без vзебез сотне эшкәртә идек; йорт хайваннары бездә яхшы vрчетелде.
Авыр сугыш елларында, кvп кенә авылдашлары кочкә-кочкә эшләп йоргәндә, Ерзиннар гаиләсе vз хужалыкларыннан туклана иде. Оста пешекче Хәлимә ин гади ризыклардан торле тәмлушкалар пешерә булган. Ә пирогларынын тәмлеге – теленне йотарлык! Инде тыныч вакытта ләмберлеләр еш кына ана туйга яки башка тантанага бәлеш пешерvне сорап морәҗәгать иткәннәр. Остәвенә, Хәлимә апа кул эшләре белән семьясын киендергән; балалары кигән киемнәр кибетнекеләрдән калышмый булган. Ун балалы Ерзиннар гаилә бюджеты очен бу бик тә моһим булган. Биш ул һәм биш кыз: Фиять, Фаиль, Камиль, Фәрит, Ринат, Левәйзә, Мянсура, Ряйсә (быел 93 яшь тула), Нурия, Румия. Алтын Йолдыз ана - героиняга 1954 елда, Хәлимәнен унынчы баласы тугач тапшыралар.
- Бу йолдыз, ядкарь кебек, безнен гаиләдә озак сакланды, - дип искә ала Камиль Алиевич. - Хәзер ул абыйнын гаиләсендә. Ә әнинен Мактау грамоталары кvпме иде! Мин әле дә, ул елларны искә тошереп, анын барысына да ничек олгергәнен анлый алмыйм.

Йорт, ярдәмче хужалык, „яшелчә” бакчасы, ун бала, остәвенә, эш. Башта колхоз ашханәсендә пешекче булып эшли, аннары хужалыкта. Әни башка хатыннар белән бергәләп vсентеләр vстерә, башка йомышларны да vти иде. Шул ук вакытта безне, балаларны, әти-әниләр кечкенәдән vк эшкә ойрәттеләр, һәркайсынын хужалык буенча vз вазифалары бар иде. Сонынннан бу «университетлар» бик ярап куйды! Кечкенәдән vк безгә сендергәннәре дә бар: ин моһиме – vз тормышынны лаеклы итеп яшәv, кешеләр алдында оят булмасын.

Теләсә нинди хезмәт булды безнен очен мактаулы: абыйларым машина йортvче һонәрен сайлаганда, әти-әниләр аларны кире какмады, гәрчә, могаен, кvнел тvрендә безнен барыбызнын да югары белем алуыбыз турында хыялланганнардыр. Абыйлар машина йортvчеләр булгач, сvз унаеннан, һонәр жинелләрдән тvгел! Алар пенсиягә чыкканчы намус белән эшләделәр. Сенелем Румия РОНОда баш хисапчы булды. Мин vзем, әти-әниемнен фатихасын алып, Мордовия педагогия институтынын физкультура факультетына укырга кердем. Аннары, Н.П.Огарев исемендәге МГУда психолог һонәрен алдым. Белемгә омтылыш безгә, кvрәсен, ата-аналардан мирас итеп кvчкән. Һич арттырмыйча, алар гажәеп кешеләр иде. Әтием ике урынлы саннарны акылында жинел генә тапкырлый иде. Ул минем белән кvп шогыльләнде, мәктәпкә әзерләде. Ышанмассыз, мин беренче класска кергәндә, газеталарны иркен укый идем.

Әниемә килгәндә, ул оригиналда Коръән укыды. Безнен гаиләдә Коръәннен гарәпчә борынгы басмасы озак сакланды. Шунысы игътибарга лаек, әнием нык сәламәтлек белән аерылып тора иде, ә бит ана берничә тапкыр кырда бала табарга туры килгән. Туксан яшьтә бакыйлыкка кvчте. Тугызынчы майда ул vзе очен топ бәйрәм – Жинv конен билгеләп vтте, ә унысы - юк булды. Менә шундый язмыш!

Шунысы кадерле: Ләмберә районы халкы, шулай ук язма геройлары ирле-хатынлы Ерзиннар vз балаларына кече Ватанга мәхәббәт тәрбияли алганнар. Нурия - Архангельскида, Мянсура - Пензада, Фаиль - Саранскида яши, әмма алар, һичшиксез, Ләмберәләренә кайтып йориләр. Шулай ук Ерзиннар vзләренен барлык балаларын хезмәт соючән, намуслы, олкәннәрне һәм кече Ватаннары традицияләрен хормәт итvче кешеләр итеп vстергәннәр.

Фотода беренче рәттә, сулдан унга - Румия, Мянсура, Левяйзә, Али Садретдин улы белән Хәлимә Фәйсхан кызы, Рәйсә. Алар артында, сулдан унга - Фаиль, Камиль, Фәрит һәм Ринат басып торалар.

*Наилэ НАСЫРОВА*
*“Призыв”тагы Елена Севастьянова материалы буенча эзерлэде*